государственное бюджетное общеобразовательное учреждение
Самарской области средняя общеобразовательная школа с. Старое Ермаково
муниципального района Камышлинский Самарской области

# Внеурочное мероприятие
# «Әбиемнең серле сандыгы»

Подготовила: учитель начальных классов

Ахматзянова Венера Фагимовна

2023 г.

**Әбиемнең серле сандыгы.**

**Бәйрәмнең максаты:**

Күңел ачу чараларында актив катнашырга омтылыш формалаштыру. Халкыбызның гореф-гадәтләрен, буыннан-буынга истәлек булып калган әйберләрнең исемнәрен (бала итәкле күлмәк, алъяпкыч, камзул, түбәтәй, калфак) хәтерләрендә калдыру. Шигырь һәм уеннар аша балаларны татар халкының үткәне белән таныштыруны дәвам итү. Нәфасәти зәвыкларын үстерү, әйләнә-тирәдәге предметларны бәяли белергә өйрәтү.

Татар халкына, фольклорына мәхәббәт һәм ихтирам тәрбияләү.

**Алдан эшләнгән эшләр:**

Музейга экскурсиягә бару; сандык һәм андагы әйберләр белән танышу; шигырьләр, уеннар, биюләр, мәкальләр өйрәнү.

**Материал:**

Өй күренеше, чиккән әйберләр, каба, сандык, өстәлдә самавар, татар халык ашлары.

**Чара барышы:**

Алып баручы берничә бала белән (балалар татар киемнәреннән) залга керә. (Башка балалар алдан кереп утыралар).

**Музыка уйный**

**Укытучы**: Исәнмесез,хәерле көн, кадерле балалар,хөрмәтле кунаклар!Без буген сезнең белән үткән көннәргә,әби-бабаларыбызның яшь вакытларына сәяхәткә барырбыз.Бүгенге бәйрәмебезнең исеме дә **“Әбиемнең серле сандыгы”** дип атала.

**1.**Әбиемнең серле сандыгы!
Нинди серләр саклый икән ул?
Гомер буе җыйган хәзинәме,
Әллә инде күңел бизәгеме.
Нинди серләр саклый икән ул?

**2**.Әбиемнең күңел сандыгын
Бер ачасы иде,ачасы....
Әби-бабам белгән йолаларны,
Халкыбызның күңел җәүһәрләрен
Бер ачасы иде,ачасы.

**3**.Әбиемнең серле сандыгы
Кызыктыра безне күптәннән
Ач әбием,безгә күңелеңне,
Яшь буынга мирас булып калсын,
Бер хәзинә калсын үткәннән.

**Укытучы:** Хәрбер кеше үз халкының үткәнең, бабайларның ничек көн иткәнен , ниләр белән шөгыльләнгәнен , гореф-гадәтләрен, йолаларын белергә тиеш. Чөнки үткәнен белмәгәннең киләчәге юк - ди халкыбыз.

**Укытучы:** Гасырлардан-гасырга, буыннан-буынга, әби-бабайдан әти-әнигә, әти-әнидән балага үзләренең борынгы бәйрәмнәрен, гореф-гадәтләрен, йолаларын югалтмыйча тапшырып килгән, һәм алар, күпмедер дәрәҗәдә үзгәреп, югалып бетә язып, безнең көннәргә дә килеп җиткән.

**Укытучы:** Балалар ,без бүген эбигэ кунакка барабыз . Эбинен хэллэрендэ белербез. Эбинен бер серле сандыгы бар. Шул сандыкта бик зур хэзинэлэр саклана.

**Укучы**: Әбием! Әйтергә дә онытып торам, бүген безгә минем дусларым килергә тиеш. Мин аларга синең сандыкта кадерләп саклаган милли киемнәр турында сөйләгән идем. Аларның бу әйберләрне күрәселәре килә.

**Эби:** Иптәшләреңне чакырып бик яхшы эшләгәнсез, балаларым. Сандыгымда сакланган милли киемнәр турында сөйләрмен.

**Укытучы:** -Менә килеп тә җиттек. Балалар, карагыз әле, авыл өйләре нинди матур. Халкыбыз элек-электән матур итеп йортларын бизәгән. Шакып карыйк әле. Өйдә кеше бармы? Керергә мөмкинме? (Шакыйлар. )

**Әби:** -Бәрәкәт, балалар килгән икән бит.

**Балалар:** Исәнмесез! Хәерле көн!

**Эби:** Хәерле көн, балакайларым. Күптән инде үзегезне күргәнем юк, үсептә киткәнсез. Түргә узыгыз.

**Укытучы**: Бу өйнең бизәкләрендә күңел нуры, җитез кулларның осталыгы күренә. Балалар карагыз әле, өйнең түрендә ямь биреп сандык тора.

Әбиемнең сандыгында
Сакланмый ниләр генә.
Әйдәгез сорыйк үзеннән
Ачып күрсәтсен безгә.

**Әби**: -Әйе, сандыкта халкыбызның буыннан-буынга тапшырылган күңел байлыгы саклана. Минем сандык гади сандык кына түгел бит, тылсымлы сандык. Ул сандыкны болай гына ачып булмый әле. Сез мәкальләр беләсезме соң? Мин сезгә татар халык мәкальләренең башын әйтәм, ә сез ахырын әйтерсез.

- Кем эшләми, шул (ашамый).
- Тырышкан табар, ташка (кадак кагар).
- Калган эшкә кар (ява).
- Егет кешегә җитмеш төрле (һөнәр дә аз).

**Әби**: Булдырдыгыз балалар, бик күп беләсез икән сез. Менә хәзер сандыкны ачарга була инде .Бу серле сандык безгэ истэлеккэ эбиебездэн калган .Эйдэгез эле,балалар,бу сандыкны ачып карыйк.

**Укытучы:Ай-хай,нэрсэлэр генэ юк икэн бу сандыкта**
**Эби:** Их, солгем, кадерле солгем. Кыз кеше кияугэ чыгарга ризалык билгесе

Кайсы гына егетнең иңенә ятмаган да, нинди генә батырларга бүләк

булмаган бу сөлге!.

**Укытучы**: Эби, балалар, менэ бу матур солгелэр турында шигырь дэ белэлэр. Эйдэле , кем сойлэп курсэтэ?

**Укучы**- Сөртенсәң - сөлге кирәк,

Көрәшсәң - сөлге кирәк,

Батырларга Сабан туйда

Бирелгән сөлге бүләк!

**Әби:** - Карагыз әле, балалар, ничек балкып тора бу сөлге.

Ә менә минем үзем чиккән сөлге. Бу сөлгеләр ничек чигелгән?

**Укучы-**

Бу сөлгеләр, ашъяулыклар

Тамбур белән чигелгән

Әллә инде чын чәчәкләр,

Өсләренә сибелгән.

**Эби:** Бу йөзек – әбиемнән калган истәлек. Мин аны бик кадерләп саклыйм. Аулак өйгә җыелгач, шушы йөзек белән "йөзек салыш" уйный торган идек.

Кыз: Әбекәй, безгә дә өйрәт әле шушы уенны.

**Эби:** Әйдәгез, барыгыз да тезелешеп утырыгыз, учларыгызны тотыгыз. Мин сезгә йөзек салам. Йөзек кемдә икәнне сизсәгез, аңа берәр "җәза" бирәбез **(Йөзек сала).** Йөзек кемдә, сикереп чык.

**Укытучы**: Рәхмәт, әби, бик күңелле уен булды. Тагын сандыгыңда ниләр бар соң?

**Эби:** Менэ бу яшь кызлар кия торган алъяпкыч. Монда аларнын осталыгы, унганлыгы да чагылган.

**Бала:** Ак алъяпкыч  челтэрле

Кукрэкчэсе бизэкле.

Каплавычы бизэкле,

Кырыйлатып чигуле

Чигулэре бик ямьле.

**(Әби калфак чыгара.)**
**Әби**: Балалар, кайсыгыз белә, бу нәрсә?

**Балалар**: Калфак.

**Әби**: Ә калфакны кемнәр кия?

**Балалар**: Әниләр, әбиләр, кызлар, апалар.

**Укытучы**: Әйе, хатын-кызларның өс-баш киеменең төп бизәге булып чигүле калфак тора, менә безнең кызларыбыз да сиңа кунакка килгәндә матур калфак киеп килделәр.

**Укучы**
Дәү әнием энҗе калфак
Бүләк итте үземә.
Энҗе калфак бигрәк матур,
Бик килешә йөземә.

**Укытучы**Менә безнең матур калфак кигән кызларыбыз хәзер бик матур итеп биеп тә күрсәтерләр. **(Татар халык биюе башкарыла)**

**Укытучы**:  әби, сезнең киемнәрегез кызлар өчен генә мени?

**Әби**: Нишләп? Бу түбәтәй ошамыймени?  **(Әби түбәтәй күрсәтә.)**

**Әби**: Түбәтәйне кемнәр кия, балалар?

**Балалар**: Абыйлар, бабайлар, малайлар.

**Укытучы** Әйе, бик дөрес.

***Укучы:***
Бигрәк матур түбәтәе
Энҗе бөртекләр белән
Алар монда килгән гүя
Чын әкият иленнән.
.
**Әби:** Тагын без бәйрәмнәрдә матур итеп чигеп ясалган читек кия идек.

Укучы
Бизәк төшкән итекләрне
Читекләр дип йөртәләр.
Аларны татар кызлары,
Бәйрәмнәрдә кигәннәр.

**Укытучы** Әйе, чын матурлык һәркемне сөендерә. Нинди матур бизәкле читекләр. Миңлеҗамал әби, безнең булган, батыр малайларыбыз да матур итеп татарча бии беләләр. Әйдәгез биеп күрсәтик әле. **(Малайлар биюе).**
**Әби:** Ай, булдырасыз икән сез! Ә без биегәндә чабата киеп бии идек. Чабатаның нәрсә икәнен беләсезме соң сез. Менә ул! Без үскәндә сезнеке кебек матур аяк киемнәре юк иде. Әтиләр безгә шундый чабата үреп бирә иде. Яз, көз көннәрендә аякка су үтмәсенгә астына агачтан шакмак кагалар иде.

**Укытучы:** Бу киемнәр, бу бизәкләр

Килә ерак чорлардан.

Үсәр татар балалары

Илһам алып шулардан

**Укучы**Бу байлыкны урнаштырып,

Әби сандыгын япсын.

Безнең кебек балаларга

Аны ачып күрсәтсен.

**Эби-** Әйе, балалар, сандыкның серләре күп әле. Без бүген әби-бабаларыбыздан калган хатирәләрне яңарттык. Уйнадык-көлде, җырладык-биедек. Бергәләп күңел ачтык. Мәңге сүнмәс безнең Милли сәнгатебез, һаман шулай балкып, чәчәк атып торыр.

**Укытучы**Сандыгыңның байлыгын күрсәткән өчен дә рәхмәт үзеңә, синдә күңел ачып, **халкыбызның милли сәнгате белән якыннан таныштык. Балалар, әйдәгез әбигә рәхмәт** әйтәбез.
**Балалар**: Рәхмәт, әби!
**Әби**: Сау булыгыз балалар!

**Укытучы**

Хәтерләүдән курыкмагыз сез!
Үткәнегезне онытмагыз сез.
Белегез сез ерак бабаларның,
Ничек итеп көн иткәнен..
Ни иккәнен,ни чиккәнен,
Нинди җырлар,нинди моңнар
Безгә калдырып киткәнен.

**Укучы**

Без-татарлар, шушы исем белән

Җирдә яшәү-үзе зур бәхет.

Яшибез без бу җирдә

Бар халыклар белән берләшеп.

**Укучы**

Туган җирем!

Һәр телнең бар туган иле

Туган җирем кебек назлы

Җырдай моңлы татар теле.

**Укучы**

Матурлыкка бай ул безнең тормыш

Адым саен анда матурлык

Барлык батырлыкның, матурлыкның

Ижат итучесе-халык бит.

**Песня “Туган тел”**

Шуның белән әбиемнең серле сандыгы аша үткәннәргә сәяхәтебез тәмам.Сезнең дә күңел сандыкларыгыз саекмасын,һәрчак тулыланып,баеп торсын! Исэн-сау булыгыз!